ӘНИЛӘРГӘ СӨЕНЧЕ

Вакытыннан алда эшкә чыксалар да, пособие түләнәчәк

> 2

ЯҢАСЫ АЧЫКЛАНГАН

Чәчәк авыруыннан кала, йогышлы авырулар берсе дә тормышыбыздан югалмады

> 7

РИМА САФИУЛЛОВА:

«Ир – баш, хатын – муен. Гаиләдә шулай булырга тиеш»

> 7

САБАН ТУЕ КАЙТАВАЗЫ

Киемгә карап каршы алдылар

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 90 (29057) | Сишәмбе | 27 июнь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Зөһрә САДЫЙКОВА

СЫНАЛУ

Һава торышы игенчеләрне сынавын дәвам итә. Майда кырау сугып, шактый культураларга зыян килгән иде. Инде җәйнең беренче ае да явым-төшем белән дә, җылы белән дә сөендерми. Синоптиклар да, аграрийлар да аптырашта. Игенчеләр алдан фаразларга яратмаса да, кайбер районнарда узган елгы уңышның яртысына гына өметләнәләр. Кайсы районнарда вазгыять аеруча катлаулы?

vk.com

Корылык

КФУның метеорология, климатология һәм атмосфера экологиясе кафедрасы мөдире, профессор Юрий Переведенцев сүзләренчә, 20 июньгә кадәр Казанда нибары 8,5 мм явым-төшем булган. Ә июньдә аның нормасы 68 мм булырга тиеш. Республикада корылык хөкем сөрүен синоптик та инкарь итмәде.

– Татарстанда, чыннан да, корылык күзәтәбез. Бу хәл инде апрельдән үк бара. Безнең метеостанция мәгълүматлары буенча, апрельдә 40 мм урынына явым-төшем нибары 3 мм гына булды. Майда норма буенча 39 мм буласы иде, тик бу айда да 26 мм гына явып узды, – диде ул.

Татарстанның Гидрометеоүзәге нәтиҗәләре дә куандырмый. Үзәк җитәкчесе Феликс Гоголь белдергәнчә, туфрак апрельдән бирле суга тилмерә. Бу айда явым-төшем норманың 5–55 процентын гына тәшкил иткән. Майда республиканың көнчыгыш районнарында 25 мм (норманың 5–55 проценты) булса, көнчыгышында хәлләр бераз уңайрак иде. Әлеге зонадагы районнарда явым-төшем уртача 30–55 миллиметрны тәшкил иткән. Бу – норманың 80–130 проценты.

– Июньнең икенче яртысында вазгыять тагын да катлауланды. Кайбер районнарда явым-төшем норманың 15 процентын гына тәшкил итте. Ә Мөслим, Әлмәт, Бөгелмә районнарында бөтенләй бер тамчы яңгыр төшмәде. Калган районнарда да норманың нибары 5 проценты гына явып узды. Бик зур дефицит, – диде Феликс Гоголь.

Азык җиткерү

Мөслим районында май кыраулары 3000 гектар рапс басуларына зыян салган иде. Районның авыл хуҗалыгы һәм азыктөлек идарәсе башлыгы Ренат Вәлиев әйтүенчә, алар тишелеп чыгып, үсеп утыра.

– Май суыклары люцерна басуларына да тиде. Корымасалар да, саргаеп, үсеш тукталып торды. Шуңа күрә беренче чабуда уңыш азрак булды. Узган елларда гектарыннан 180–200 центнер алган булсак, быел бер гектардан 36 центнер печән чыкты. Әле ярый узган елгы запасларыбыз бар. «Август – Мөслим» агрохолдингы бу яктан сынатмады, моннан тыш 1000 гектарда кукуруз бар. Яңгыр яуган очракта, шуңа ышанып торабыз. Люцернаны икенче кат чабуга да өмет зурдан түгел. Гомумән алганда, быел районда 3–4 тапкыр кимрәк терлек азыгы әзерләнә. Ләкин үзебезнең малларны ашатырга җитәчәк, – диде Ренат Вәлиев.

Җитәкче әйтүенчә, быел урып-җыю кампаниясе дә иртәрәк башланырга мөмкин.

– Вазгыятьне начар дип бәяләсәк, дөресрәк булыр, – диде ул. – Чөнки ике айда бездә 15 мм яңгыр яуды. Белгечләр корылыкның һавада да, туфракта да булуын расладылар. Басулар ярылып, үсемлекләр саргаеп утыра. Урып-җыюга да быел иртәрәк керешәчәкбез. 5–10 июльдә үк көзге культураларга тотынырбыз дип торабыз.

Ренат Вәлиев фаразлавынча, бөртекледәрдән гектарыннан 15–20 центнер уңыш чыгарга мөмкин. Чагыштыру өчен: узган ел алар 39 центнер ашлык җыеп алуга ирешкән иде.

– Уҗымнарга яңгыр бераз эләкте әле, ә менә язгы культураларның уңышы начар булыр кебек. Без инде үз чиратыбызда мөмкин кадәр корылыкка каршы көрәш алып барабыз. Игеннәрне туклындырабыз, бөҗәкләргә каршы чаралар кулланабыз. Ләкин корылык булу сәбәпле, ашлама да тиешле нәтиҗәне бирә алмый, – диде ул.

Аксубай районының Яңа Ибрай авылы фермеры Ильяс Сөләйманов без шалтыраткан вакытта көзге бодайны сенажга салып йөри иде.

– Быел нишләргә дә белгән юк, аптыраган. 2010 ел кебек үк булмаса да, хәлләр начар әле, – диде ул, көрсенеп. – Күрше авыллар бераз яңгыр күрсә дә, бездә ул булмады. Май кырауларыннан исән-имин чыккан идек. Ул вакытта суык бераз гына люцернага тиде. Төп игътибарны терлек азыгы әзерләүгә бирергә кирәк. Бер дә булмаганда, ашлыкны сатып та алырга мөмкин. Башка елларны ашлыгы да, үләне дә җитеп бара иде. Узган елдан калган запас көзгә кадәр җитәрлек кенә.

Фермерның 200 баш терлеге бар. Җирләре исә 350 гектар гына.

– 200 баш малга 2 тонна азык кирәк. Быел бөтен өмет кукурузда, ләкин яңгыр яумаса, анысы да булмас. Болай дәвам итсә, 40–50 баш терлекне кыскартмый хәл юк. Бөтенесен бетереп, кредитларымны ябып кына куяр идем дә, сыерларны алучы юк. Малларым да кызганыч. Барысы да токымлы, яхшы сөт бирә торган. Минем генә түгел, башкаларның да кәефләре шулайрак. Халык та көзгә малларын бетерү турында уйлый башлады. Терлеген бер бетергән кеше башка алмый инде ул, – диде Ильяс Сөләйманов.

Ахыры 2 нче биттә >

КОРБАН ГАЕТЕ МӨБАРӘК БУЛСЫН!



Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм МИҢНЕХАНОВның Корбан бәйрәме уңаеннан МӨРӘҖӘГАТЕ

Кадерле татарстанлылар!

Республикабыз мөселманнарын һәм барлык ватандашларыбызны чын йөрәктән Гайд әл-Әдъхә – Корбан гаете уңаеннан тәбрик итәм!

Бу шатлыклы көндә мәчетләрнең һәрберсендә намаз уку аеруча тантаналы төс ала, дин тотучылар Аллаһка киң рәхмәте, мәрхәмәте өчен мактау сүзләрен җиткерә, иман байлыгы, тынычлык һәм иминлек сорап мөрәҗәгать итә. Хаҗ сәфәрендәме ул, эштәме яисә хәрби хезмәттәме – кайда гына булуына карамастан, һәрбер мөселманга Корбан бәйрәме, үз гамәлләренә ата-бабаларның изге васыятьләрен һәм әманәтләрен өлге итеп, гаделлек һәм игелек идеалларына тугры булырга кирәклеген искәртә.

Корбан бәйрәме – хәерле эш-гамәлләр башкарыла, фәкыйрьләргә һәм авыруларга шәфкать-мәрхәмәт күрсәтелә, ата-аналарыбызны олылау, өлкәннәрне хөрмәтләү хисләрен тагын да көчәйтә торган вакыт. Кешеләрдә ул һәрчак матур киләчәккә якты өметләр уята.

Милләтләр һәм диннәр арасында күркәм хезмәттәшлек традицияләре белән дан тоткан Татарстанда һәр Корбан бәйрәмендә тантаналы һәм тәэсирле вакыйгалар күп була. Быел ул мөселман дөньясы илләре белән рухи берләшү, теләктәшлек шартларында уза. Күптән түгел аларның күпсанлы вәкилләре республикабызга килеп, «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum 2023» халыкара икътисадый форумында һәм «Россия – Ислам дөньясы» стратегик караш төркеме утырышында катнашты.

Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен рәсми рәвештә кабул итүгә багышланган чаралар хәзер тагын да киң колач алды. Татар дин әһелләренең XIII бөтенроссия форумы һәм ел саен уздырыла торган «Изге Болгар җыены» – шулардан иң күренеклеләре. Татарстанның мөселман өммәте актив катнашуы нәтиҗәсендә без республикабызның ислам хезмәттәшлеге һәм цивилизацияләр арасындагы бәйләнешларны үстерү өчен тиңе булмаган мәйданчык дигән абруен тагын да ныгытуга ирешербез дип ышанам.

Һәрберегезгә сәламәтлек, күңел күтәренкелеге һәм бәрәкәтле гомер, Корбан бәйрәмен, аның изге рухына лаеклы булганча, зурлап үткәрүегезне телим. Барлык игелекле башлангычларыгызда сезне Аллаһы Тәгалә ярдәменнән ташламасын!

Бәйрәм мөбарәк булсын, хөрмәтле татарстанлылар!

Тагын 1,5 миллиард сум

Ташламага ия кешеләр өчен дарулар сатып алуга федераль бюджетта 2023 елда 48,2 миллиард сум акча каралган. Бу максатларга Хөкүмәт тагын 1,5 миллиард сум бүлеп бирәчәк. «Бу акча дәүләттән ярдәм алучы кешеләр өчен даруларны өстәмә рәвештә сатып алырга мөмкинлек бирәчәк», – диде Премьер-министр Михаил Мишустин утырышта.

Татарстанга исә шул акчаның 48,7 миллион сумы эләгәчәк. Социаль ярдәм инвалидларга, шул исәптән Бөек Ватан сугышында катнашканнарга, инвалид балаларга, чернобыльчеләргә бирелә.

Быел социаль ярдәм чаралар җыелмасын өлешчә яки тулысынча алу хокукына Казанда яшәүче 95 меңнән артык кеше ия. Әлеге җыелма түләүсез дарулар һәм медицина эшләнмәләре, шифаханә-курортта дәвалануга юлламалар, шәһәр яны электр поездларында йөрү өчен ташламаларны үз эченә ала. Ай саен бирелә торган акчалата түләү күләме кайсы социаль хезмәтләрне сайлауга бәйле булачак.

Эсселек килә

Республика Гидрометеоүзәге фаразлары буенча, бу атнада +28 градуска кадәр җылыта, яңгырлар булырга мөмкин.

Сишәмбе һәм чәршәмбе көннәрендә Татарстан югары атмосфера басымы астында кала. Төнлә +5...+13 градус җылы булса, көндез +21...+28 градус булыр дип көтелә. Явым-төшем ихтималы аз.

Пәнҗешәмбе, 29 июньдә, көндез кыска вакытлы яңгыр булуы ихтимал, һава +22...+27 градуска кадәр җылыначак.

Гидрометеоүзәк фаразлары буенча, җомга һәм шимбә көннәрендә яңгырлар көтелә, урыны белән яшен һәм көчле җил. Көндезге температура +22...+28 градус.

Мәгълүм булганча, Татарстанда июнь ае буе диярлек һава торышы салкынча торды. Кайбер көннәрдә тәүлеклек уртача температура нормадан 6–9 градуска кадәр төште. Төнлә кыраулар да булды.

Изге бәйрәм

Якынаю көне

Иртәгә барча мөселманнар изге бәйрәмебез – Корбан гаетен билгеләп үтәчәк. Бу көнне һәркайсыбыз, дөнья эшләрен читкә куеп, вакытны гыйбадәт, туганнарның хәлен белү, бер-береңне котлау, изге теләкләр теләү кебек савaплы гамәлләр белән уздыра.

Мәчетләрдә Корбан гаете уздыру тәртибе:
2.30 – 03.00 сәг. – Коръән уку;
03.00 – 03.30 сәг. – гает вәгазе сөйләү;
03.30 сәг. – гает намазын уку;
03.40 сәг. – гарәп телендә хөтбә,
Коръән укып дога кылу.

Чәршәмбегә каршы төндә мәчетләребездә бәйрәм вәгазе сөйләнеләчәк. Иртәнге дүртенче яртыда гает намазы укылачак.

Гает намазыннан соң, гадәттәгечә, махсус билгеләнгән урыннарда корбан чалу башланачак. Быел Татарстан күләмендә 55 урында корбан чалыначак. Узган ел бәйрәм көннәрендә республикадагы рәсми рөхсәт ителгән мәйданчыкларда 12,3 мең хайван чалынган. Быел корбан нисабы күләме – 36 мең сум. Ягъни ихтыяҗларыннан тыш кулында 36 мең сум ирекле акчага ия кеше Корбан бәйрәмендә сарык чалырга тиеш.

«Корбан» дигән сүз гарәп теленнән «якынаю» дип тәрҗемә ителә. Аллаһы Тәгаләнең безгә биргән санаусыз нигъмәтләренә шөкер йөзеннән корбан чалып, аңа якынаю көне бу. Корбанлык сатып алырга акчасы җиткән, акыллы, балигъ булган, ирекле кешегә корбан чалу ваҗиб санала. Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев белдерүенчә, гаиләдә һәркем исеменнән корбан чалынырга тиеш дигән мәҗбүри таләп юк.

– Әгәр гаиләнең акчасы уртак, бер кулда гына икән, ул бер кеше исеменнән – йорт хуҗасы булган ир-ат исеменнән чалына. Андый чакта гаиләдә һәркем исеменнән корбан чалынырга тиеш дигән мәҗбүри таләп юк. Әгәр гаиләдәге һәркемдә нисабка җиткән артык акча булса, ул һәр кеше исеменнән дә чалына. Әйтик, ирнең дә, хатынның да 36шар мең сумлык нисаб күләменә җитәрлек акчасы бар, ди. Алар икесе дә корбан чалдыра. Җиткән баланың да нисаблык акчасы булса, ул да корбан чалырга тиеш, – дип ачыклык кертте Татарстанның баш казые «ВТ» хәбәрчесенә.

Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе белгечләре корбанга сарыкларны үзебездән алырга киңәш итә. Ник дигәндә, читтән республикага чир керергә мөмкин, дип кисәтә алар.

Татарстан Диния нәзарәтеннән хәбәр итүләренчә, 27, 28, 29, 30 июнь, 1 июль көннәрендә Тәкбир әт-Тәшрик көннәре билгеләп үтелә. Бу көннәрдә (27 июньдә иртәнге намаздан башлап 1 июльдә икенде намазын кертеп), фарыз намазларыннан соң (барлыгы 23 тапкыр), сәлам биргәч, тәкбир-тәшрик әйтелә: «Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр. Ләә иләәһә илләллааһу вәллааһу әкбәр. Аллааһу әкбәр вә лилләәһил-хәмд». Ирләр тәкбирне тавыш белән, хатын-кызлар эчтән генә әйтергә тиеш.

27 июнь – Гарәфә көне. Бу көнне тотылган ураза иң кадерлеләрдән санала. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә: «Гарәфә көнендә ураза тоткан кешегә Аллаһ үткән һәм киләсе елның гөнаһларын гафу итәр дип өметләнәм», – дигән.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Сүзгә-сүз

Елена ЯМПОЛЬСКАЯ, Дәүләт Думасының мәдәният буенча комитет рәисе:

Бездә мәктәпләр, медицина учреждениеләре якланган. Хәзер исә мәдәният учреждениеләре өчен дә закон нигезендә броня һәм фильтр куясы иде. Чөнки алар оптимальләштерү, тузган торак, кеше аз йөри, авыл кечкенә дигән сәбәпләр белән юкка чыгарыла да һәм анда тормыш бетә. Моңа юл куярга ярамый.

(«Парламентская газета»дан)

РОССИЯДӘ – ДУСЛЫК

Соңгы 12 елда Россиядә якын дуслары булмаган кешеләрнең саны 1,5 тапкыр арткан. SuperJob хезмәте белгечләре уздырган сораштыру нәтиҗәләре әнә шул хакта сөйли.

Сезнең иң якын дустыгыз ир-атмы, хатын-кызмы?

Җаваплар	Сораштыруда катнашучылар	Җенес					
		Ир-атлар Яше			Хатын-кызлар Яше		
		34кә кадәр	35–44	45тән өлкәнрәк	34кә кадәр	35–44	45тән өлкәнрәк
Ир-ат	37%	55%	50%	46%	24%	19%	20%
Хатын-кыз	29%	10%	16%	23%	48%	46%	42%
Минем якын дустым юк	34%	35%	34%	31%	28%	35%	38%



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

«ТИТАНИК» АРТЫННАН КИТКӘН «ТИТАН»

Үткән атнада дөньякүләм символик мәгънәгә ия вакыйга булды: Американың OceanGate компаниясе милке – «Титан» батискафы 1912 елда һәлакәткә очраган «Титаник» лайнеры ватыклары янына туристик сәяхәт ясау нияте белән океан төбенә төшеп югалды. Су асты аппараты, океан төбенә төшә башлауга ике сәгать тирәсе вакыт үтүгә, элемтәгә чыгудан туктаган. 3 километр тирәсе тирәнлектәге аппаратка ярдәм итү мөмкинлеге табылмады. Баштарак экипаж үз көче белән һәлакәттән котылыр дигән өмет бар иде. 23 июньдә оператор-компания батискаф экипажының һәлак булуын игълан итте. Су төбендәгеләрнең һава запасы шул көнне беткән. Соңрак инде су асты аппаратының ватыклары да табылды дигән хәбәрләр күренде. Фаҗиганең сәбәбе шартлау булырга тиеш дигән беренче нәтиҗә ясалды. Батискафта урыннар кыйммәт: бер билет 250 мең доллар тора, диделәр. Аның бортында британ миллиардеры Хэмиш Хардинг, OceanGate Expeditions компаниясенә нигез салган Стоктон Раш, француз акванавты Поль-Анри Наржоле, пакьстанлы бизнесмен Шәхзада Давыд, аның улы Сөләйман Давыд булган.

Кешелек цивилизациясе нинди генә технологик үсешкә ирешмәсен, мондый техноген катастрофалар алдында көчсез булып кала. Миллиардлар иясе булсаң да, беркем дә ярдәм итә алмый. Фаҗигадән шундый сабак нәтиҗә ясарга мөмкин. Экспедицияне оештыручы компания куркынычсызлык техникасын бозган, белгечләр ярдәменнән файдаланмаган дигән хәбәрләр дә бар.

Дөнья икътисады да шул батискаф хәлендә бүген. Кризис тирәнлегенә төшү дәвам итә. Германиянең Deutsche bank 10 процент хезмәткәрләрен кыскарта, диләр. Кыскарту яхшы тормыштан түгел. Моны барыбыз да беләбез. Англия банкы төп ставканы 5 процентка кадәр күтәрде. Бу – соңгы 15 елдагы иң зур ставка. Бөекбританиянең әҗәтләре күләме 1961 елдан соң беренче тапкыр эчке тулай продукт күләмен узып китте. Төп ставканың күтәрелүе әҗәтләрнең кызурак темплар белән үсүенә китерә һәм биржа түнтәрелешен әзерли – болары да мәгълүм. АКШта төп ставканы ФРСның соңгы утырышында үзгәрешсез калдырдылар, әмма Кливлендтагы конференциядә ФРС вәкиле Мишель Боуман, инфляцияне тотып тору өчен, ставканы өстәмә рәвештә күтәрергә кирәк булачагын белдерде. Яхшы тормыштан эшләнми болар берсе дә. Процент ставкаларының күтәрелүе резерв валюталарын кыйммәтләндерә, чимал бәяләре түбәнгә китә. Глобаль базарда без шуларны күрәбез дә инде.

Икътисад түнтәрелешенә табигать бәла-казалары да үз өлешен кертә. Европада тагын аномаль корылык һәм эсселек. Уңыш кими, елгалар саегып, ГЭСлар энергия җитештерүне туктаталар. Эссе вакытта җил станцияләре дә туктап кала, чөнки һава хәрәкәте акрыная. Суыту өчен исә энергия кыш көненә караганда да күбрәк таләп ителә. Кытайда су басуга әзерләнәләр. Планетаның башка почмакларында да экстремаль һава торышы саклана.

Россиядә

ЯЛ КӨНЕ ФЕТНӘСЕ

Россиядә җомгадан шимбәгә каршы төн гадәттән тыш яңалыклар фонында үтте. Пригожин җитәкләгән «Вагнер» хосусый хәрби компаниясе, көтмәгәндә илнең Оборона министры Шойгу һәм Генераль штаб җитәкчесе Герасимовны хыянәттә гаепләп, хәрби фетнә күтәрде. Пригожин күптән инде рәсми хәрби җитәкчелек белән конфликтта, аның Россия армиясен дискредитацияләп ясаган чыгышларына югары җитәкчелек тиешле игътибарны биреп җиткермәде. Оборона министрлыгы бәйсез хосусый хәрби берләшмәләрне үз канаты астына җыярга тотынган иде тотынуын. Путин да министрлыкны яклады, чөнки илдә авыр хәрби техника белән коралланган бик күп хәрби компанияләр барлыкка килә башлады. Россия законнары буенча хосусый хәрби берләшмәләр тоту тыелган булуга карамастан, махсус хәрби операция фонында алар ишәйде һәм үсте. Дөрес, аларны закон кырына куып кертү буенча да эш алып барылды. «Вагнер» берләшмәсе исә, Сүриядәге сугыш елларында ук оешып, үзен нәтиҗәле итеп күрсәтте. Башка илләргә таралып, эш алып бара башлады. Зур империягә әверелә язды. Украина конфликтында катнашу дәвамында Пригожин үзен чамасыз бәйсез фигура буларак күрсәтте. 1 июльгә Россиядә Оборона министрлыгы барлык хәрби берләшмәләрне дә үз кулы астына алып бетерергә тиеш иде. Дата якынлашкан саен, «Вагнер» җитәкчелеге фетнәчел белдерүләрен ешайтты һәм ял көннәре алдыннан, ва-банкка барып, коралды фетнә башлап җибәрде. Сылтау итеп, оборона министры Шойгу әмере белән «Вагнер» сугышчыларына ут ачып, үтереш башланды дигән хәбәр алынды. Газета хәбәрчесе вакыйгаларның агышын төн дәвамында күзәтеп торды. «Российская газета»ның телеграм-каналы төнге бер туларга 12 минут кала Террорга каршы милли комитетның Евгений Пригожин тарафыннан таратылган раслауларның нигезсез булуын һәм фетнәгә чакыру факты буенча җинаять эше ачылуын хәбәр иткән белдерүен элде. Шуңа карамастан, гыйсъянчылык хәрәкәте дәвам итте. Пригожинчылар иртәнгә инде Ростовны кулларына төшерделәр, Мәскәүгә таба хәрәкәт башланды. Путинның аларны хыянәттә гаепләгән чыгышы да, кайбер генералларның акылга килергә чакырулары да нәтиҗә бирмәде. Дөрес, яшен тизлегендә башланган һәм каршылык күрмичә диярлек барган бунт аннан да тизрәк тәгәлләнде дә. Путин үтенече буенча Лукашенко Пригожин белән сөйләшүләр алып барган икән, кичкә фетнәче тәртәләрне кире борырга килеште. Бу уңайдан мәгълүмат кырында бик күп фейклар таратыла. Вазгыять бик томанлы, әлбәттә. Әмма иң мөһиме: каршылык гражданнар сугышына әйләнеп китмәде. Күп кан коелмады. Массалар нейтралитет күрсәттеләр, фетнәчеләрне яклаган массакүләм чыгышлар булмады. Җавапсыз бик сораулар калды, билгеле. Аларның чишелеше эзләнә дип аңлыйк.

РӘИС КӨНДӘЛЕГЕ

tatarstan.ru

Горур кешеләр

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов «Казан дәүләт казна дары заводы»на 235 ел тулу уңаеннан тантаналы чарада катнашты.

Рәис әйтүенчә, заводны хезмәткәрләре үзенчәлекле итә. Бүген биредә 2,5 меңнән артык кеше эшли.

– Бу – үз һөнәренең чын осталары. Һәр хезмәткәргә тырышлыгы өчен рәхмәт әйтәсем килә, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Тантаналы чарада завод ветераннарына да ихлас теләкләр җиткерделәр.

– Сез – хезмәт династияләренә нигез салучылар, – диде Рәис. – Сезнең тырышлыгыгыз һәм тәҗрибәгез яшь хезмәткәрләргә үрнәк булып тора. Бүген предприятие күп очракта нәкъ менә сез башкарган эш хисабына үсә.

Рөстәм Миңнеханов заводка алга таба да яңа хезмәт җиңүләре һәм үсеш теләде.

– Хезмәткәрләребез – заводның горурлыгы, – диде федераль казна предприятиесе генераль директоры Александр Лившиц. – Заводта 160 хезмәт династиясе бар.

Тантаналы чара кысасында Рәис завод тарихына багышланган күргәзмәне карады, завод ветераннары белән дә аралашты.

Игелек бөҗрасы

Шул ук көнне Рөстәм Миңнеханов Хөкүмәт йортында «Круг добра» фонды идарәсе җитәкчесе Александр Ткаченко белән очрашты.

Исегезгә төшерәбез, фонд Россия Президенты Указы нигезендә 2021 елда оешты. Аның төп бурычы сирәк очрый торган авырулары булган балаларга ярдәм итүдән гыйбарәт. Очрашу барышында Рөстәм Миңнеханов һәм Александр Ткаченко Татарстан белән фонд арасында хезмәттәшлек турында сөйләштеләр. Хәзерге вакытта республикада яшәүче 200ләп бала фонд аша дарулар белән тәэмин ителә.

Сыйфатны тикшерәләр

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Указы нигезендә Республикада яшәүче гражданнарның тормыш сыйфатын яхшырту мәсьәләләре буенча совет барлыкка килде.

Советны Рәис үзе җитәкли, урынбасары – Татарстанның вице-премьеры Ләйлә Фазлыева, секретаре – республика хезмәт министры урынбасары Юлия Абдреева.

Ул Татарстан территориясендә Милли социаль инициативаны гамәлгә ашыру, төбәк социаль стандартын кертү һәм Татарстан халыкларының социаль хезмәт күрсәтүдән канәгатьлек дәрәҗәсен күтәрү максатыннан оештырыла. Бу эшчәнлек төрле юнәлешләргә – сәламәтлек саклау, мәгариф, хезмәт белән тәэмин итү һәм халыкны социаль яклау, шулай ук яшьләр сәясәте һәм шәһәр үсеше өлкәсендәге мәсьәләләргә кагыла. Аның төп бурычлары – республикада дәүләтнең социаль тармактагы сәясәтен тормышка ашыру өстенлекләре буенча тәкъдимнәр формалаштыру, бу өлкәдә законнарны камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү, шулай ук өстенлекле проектларны һәм аларның нәтиҗәләрен карап тикшерү. Шулай ук совет гражданнарның тормыш сыйфатын ачыклау буенча үткәрелгән рейтинг нәтиҗәләрен анализлау барышында катнашу, гражданнарның фикерләрен искә алып, «Яңа проектларны эшләү буенча стратегик инициативалар агентлыгы» рейтингында Татарстан позициясен ныгыту өчен тәкъдимнәр әзерләү һәм башка мәсьәләләр белән дә шөгыльләнәчәк.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Завод коллективының илебез оборона мөмкинлекләрен ныгытуда аеруча мөһим казанышларга ирешүе өчен **«Казан дәүләт казна дары заводы» федераль казна предприятиесе «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены** белән бүләкләнде.

***

«Казан дәүләт казна дары заводы» федераль казна предприятиесенең 3 номерлы участогы 8 номерлы цехы токаре **Габделганиев** Наил Нурмөхәмәт улына, «КАМАЗ» гавами акционер җәмгыятенең пресс-рам заводы директоры **Птичкин** Сергей Николаевичка, «Гамәли оптика дәүләт институты» фәнни-җитештерү берләшмәсе» акционер җәмгыяте җир өсте комплексларының җылылык үлчәү приборлары бүлеге башлыгы **Рагинов** Сергей Владимировичка, «Казан дәүләт казна дары заводы» федераль казна предприятиесенең 3 номерлы участогы 8 номерлы цехы участок башлыгы (сәнәгатьтә) **Хәбибуллин** Адель Андреевичка **«Татарстан Республикасының атказанган машина төзүчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Казан дәүләт казна дары заводы» федераль казна предприятиесе хезмәткәрләре: 54 номерлы участогы 7 номерлы цехының химик анализ лаборанты **Гайфиева** Раушания Азат кызына, 2 номерлы участогы 5 номерлы цехының комплекслы җайланма аппаратчысы **Морозова** Надежда Наил кызына, продукциянең сыйфатына идарә юнәлеше җитәкчесе – 31 номерлы цехның техник контроль бүлеге башлыгы **Туюшева** Адилә Илдус кызына, 31 номерлы участогы 31 номерлы цехының 3 нче цехы производство контролеры **Фәхретдинова** Зөлфия Искәндәр кызына **«Татарстан Республикасының атказанган химигы»** дигән мактаулы исем бирелде.

Сыналу

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

«Гадәттән тыш хәл» кирәк

Татарстанның Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте буенча комитет рәисе урынбасары Таһир Һадиев фикеренчә, кайбер районнарда гадәттән тыш хәл игълан итү дә комачауламас иде.

– Мәсәлән, яз һәм җәй көннәрендә Ютазы һәм башка районнарда явым-төшем бик аз булды. Анда корылык һавада гына түгел, туфракта да сизелә. Азнакай, Әлмәт, Баулы районнарында да шул ук хәл күзәтелә. Бу районнарда гадәттән тыш хәл игълан итү бик нигезле булыр иде, – ди ул. – Чөнки санап үтелгән районнарда терлек азыгы әзерләү буенча проблемалар бар. Иген уңышы да кимрәк булачак. Бүген терлек азыгы узган елга караганда шактый кимрәк. Ә азык белән шәхси хуҗалыкларны да тәэмин итәргә кирәк бит. Шул ук вакытта республиканың төньяк өлешендә терлек азыгы әзерләү буенча яхшы күрсәткечләргә ия булган районнар да бар. Дөрес, бу район һәм хуҗалыкларда яңгыр күбрәк яуды, әмма алар килеп туган шартларга җайлашырга тырышалар, тиешле технологияләр кулланалар.

Таһир Һадиев корылыкка каршы тора алырдай чаралар кулланырга кирәклегенә басым ясады.

– Бүген республиканың барлык территориясенә дә яңгыр кирәк. Һава торышы белән килеп чыккан вазгыятьне ничек бар, шулай кабул итәргә генә кала. Корылыкка каршы тору өчен, белгечләр һәм галимнәр агротехник чаралар комплексын эшләргә тиеш. Татарстанда корылык еш «кунак»: ике-өч елга бер тапкыр булып тора. Аны танырга һәм каршы тора алырлык чаралар эзләргә туры килә, – ди ул.

Татарстанның кайсы районнарында явым-төшем аеруча аз?

Районнар	Быелның 1 маеннан 20 июненә кадәр булган явым-төшем, мм
Чирмешән	5
Сарман	8
Тукай	9
Кукмара	13
Тәтеш	13
Түбән Кама	13
Лениногорск	15
Мөслим	15
Ютазы	17
Азнакай	17
Зәй	17
Алабуга	18
Әтнә	20
Әгерҗе	21
Минзәлә	21

Мәгълүматлар республиканың Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгыннан алынды.

ТАБАРГА ЯРАМЫЙ ЭШЛӘРГӘ

Яңалык

Әниләрне сөендерделәр. Россия Президенты Владимир Путин яшь ярымга кадәр бала белән өйдә утыручы хатын-кызларга билгеләнгән айлык пособиене, вакытыннан алда эшкә чыксалар да, ничек бар шулай түләргә тәкъдим итте. Бишектәге сабый эшкә комачау итми икән, бигайбә! Белгечләр исә бер кат кискәнче, җиде кат уйларга киңәш итә. Кечкенә балалы хезмәткәрдән ни файда?

Илдар Мөхәммәтҗанов/фото бизәү өчен бирелде

Казанда яшәүче Әминә Шәрәфиева тугыз айлык кызы белән декрет ялында утыра.

– Башкаладагы зур сәүдә үзәкләренең берсендә директор урынбасары булып эшләдем. Хәзер декрет ялында. Әмилә – безнең беренче балабыз. Яшь ярымга кадәр аена 23 мең сум чамасы пособие алам. Гаиләдә ике кеше өйдә утыруын исәпкә алсаң, бу – күп түгел, әлбәттә. Декрет ялына китәр алдыннан: «Тиз генә бәби табам да, кызымны әниемә калдырып, ярты көнгә кире эшкә чыгам», – дип хыялланган идем. Кем әйтмешли, йөк әле дә шул урында. Баланың мең төрле мәшәкате бар икән шул, – ди яшь әни.

Петербург халыкара икътисадый форумында чыгыш ясаганда, Владимир Путин бер яшь ярымга кадәр билгеләнгән пособиене, шулай ук бердәм бала акчасын (ул өч яшькә кадәр бала тәрбияләүче гаиләнең кереме төбәктәге яшәү минимумыннан түбән булганнарга 12 айга билгеләнә. – **Ред**.), гаиләнең матди хәле үзгәрүгә дә карамастан, түләү вакыты беткәнче ничек бар шулай калдырырга тәкъдим итте.

– Югыйсә, гаиләнең кереме бераз булса да арттымы, дәүләттән матди ярдәм чарасының күләме кими яки аны гомумән түләми башлыйлар. Димәк, әти-әниләргә тагын да тырышыбрак эшләү отышсыз. Болай булырга тиеш түгел. Социаль түләүләр хезмәт хакы белән беррәттән, керем чыганагы булып торырга тиеш, – диде Илбашы.

Әйткән сүз – аткан ук. Россия Хезмәт министрлыгы гамәлдәге кануннарга үзгәрешләр әзерләгән инде. Кечкенә балалы әниләргә кайчан һәм ничек эшкә чыгарга мөмкин икәнен дә аңлатканнар. «Яшь ярымга кадәр бала караган өчен пособие ул – иминият түләве. Аның күләме бала туганчы ике ел алган хезмәт хакының күләменә бәйле һәм ул бу акчаның 40 процентын тәшкил итә. Хезмәт кодексы нигезендә, дәүләттән матди ярдәм алучы әти яки әни вакытыннан алда тулы көнгә эшкә чыккан очракта, бу түләү туктатыла, – дигән Россия хезмәт министры Антон Котяков. – Президент тәкъдиме нигезендә, киләчәктә пособие түләгәндә гаиләнең матди хәле үзгәрү исәпкә алынмаячак. Мәсәлән, кечкенә балалы әни декрет ялы чорында башка урында эшләп торса да, аның төп эш урыны сакланачак».

Казан дәүләт аграр университеты доценты, икътисадчы Илгизәр Гайнетдинов фикеренчә, яңалык әниләрне сөендерәчәк.

– Пособие хисабына гына гаиләне артык тәэмин итеп бетереп булмый. Бала табучы хатын-кызлар арасында яхшы акчалы урында эшләүчеләр дә бар бит. Мондый әниләр яңалыкны хуплаячак, дип саныйм. Эшкә чыгарга мөмкинлегең булса, акчаның артыгы юк бит аның. Эш урынын югалтудан куркып, декрет ялын әнисенә, якын туганына рәсмиләштерүчеләр, аннан китеп, баланы үзләре генә үстерүче әниләр дә бар. Законлагы үзгәрешләр, беренче чиратта, аларга ярдәм итәчәк. Гомумән, бу – дәүләт тарафыннан уйланылган адым дип саныйм. Кечкенә балалы хезмәткәрләр белән генә ерак китеп булмый, әлбәттә. Гүзәл затларны үпкәләтәсем килми. Ир-ат буларак фикер йөртәм: хатын-кыз күбрәк өйдә булырга, бала тәрбияләү белән шөгыльләнергә тиеш. Тик тормыш булгач, төрлесе була. Шуңа күрә бу гамәлнең файдасы тиячәк. Өйдә утыручы хатын-кызларга пособие түләгәннән дәүләт күп акча югалтмый, – ди белгеч.

Рәсми мәгълүматларга караганда, 2022 елда илдә 1,7 миллион кеше бала караган өчен айлык түләү алган. Алар арасыннан 142 мең кеше (8,4 проценты) дәүләттән бирелгән матди ярдәм акчасына гына өметләнеп утырмыйча, тулы булмаган эш көне шартларында хезмәт тә иткән. Алга таба бәбиле эшчеләр саны артырмы? Монысын вакыт күрсәтер. Әмма илдә эшче көчләр җитмәве беркемгә дә сер түгел. Ә эшсезләр хатын-кызлар, бигрәк тә 40тан яшьрәкләр арасында күп, ди белгечләр. Мәсәлән, Росстаттан алынган саннарга караганда, 2021 елда бер бала тапкан хатын-кызларның – 85, ике бала үстерүчеләрнең – 78, ә өч бала әниләренең 63 проценты рәсми рәвештә эшләгән.

КЕЧКЕНӘ БАЛАСЫ БУЛГАН ХАТЫН-КЫЗЛАРГА ЭШ УРЫНЫНДА НИНДИ ТАШЛАМАЛАР КАРАЛГАН?

Булат ЗАКИРОВ, «ВТ» юристы:

– Россия Хезмәт кодексы нигезендә, бер яшь ярымга кадәр баласы булган хатын-кыз, элеккеге вазыйфасын башкара алмаган очракта, гариза нигезендә башка эшкә күчә ала. Шулай ук, 3 сәгать саен бала имезергә кимендә 30 минутлык өстәмә ял да бирелергә тиеш. Ул төшке аш вакытына өстәлергә яки берләштерелеп, эш көне башына яки ахырына күчәргә мөмкин. Мондый ял өчен гадәттәгечә түләнә. Өч яшькә кадәрге баласы булганнар тулы булмаган эш көне алып яки читтән торып эшли ала. Командировкага җибәрү, төнлә яки ялларда эшкә чыгу кебек мәсьәләләр фәкать кечкенә баласы булган хатын-кызның рөхсәте белән генә хәл ителә. Эш стажына карамастан, бала белән өйдә утыруга бәйле отпуск тәмамланганнан соң, яшь әниләргә түләүле ял бирелергә тиеш.

Мария ФИЛИНА, Гаиләләрне яклау оешмалары ассоциациясе рәисе:

– Яңалыкны хуплыйм. Әмма Хезмәт кодексына үзгәрешләр кертү белән беррәттән, дәүләт балалар бакчаларында нәниләр төркемнәре булдырырга һәм аналар, чынлап та, дәүләт ярдәменнән файдалана алсын өчен, сабыйларны канун нигезендә бакчада урын белән тәэмин итәргә кирәк. Әлегә исә ил төбәкләрендә өч һәм аннан өлкәнрәк балаларга да бакчада урын җитми.

Балалар психологы Венера Касыймова исә, сабый һәм эш арасында алтын урталык булырга тиеш, ди.

– Статистика мәгълүматларына караганда, бүген эшләүче әниләрнең 90 проценты, балага тиешле игътибар бирә алмыйм дип, үзен гаепле хис итә. Белгеч буларак шуны әйтәсем килә: хатын-кыз эшләүдән куркырга тиеш түгел. Балага аның янәшәсендә көн буе утыру түгел, җылы мөнәсәбәтләр кирәк. Тик мәсьәләнең икенче ягы да бар: бүген күп кенә хатын-кызлар, карьера ясыйм дип, бишектәге баланы калдырып, тизрәк эшкә чыгарга омтыла. Сабыйга няня яллау, нәниләр бакчасына йөртүнең кыйммәткә төшүен дә уйлап тормыйлар хәтта. Баланы карауның бер сәгате уртача 250–300 сум, коммерцияле бакчаларда түләү исә аена 18–20 мең сумнан башлана бит. Иң яхшысы – ике яшькә кадәр сабый әнисе янында булырга тиеш, – ди балалар психологы.

Эльвира ВӘЛИЕВА

РИМА САФИУЛЛОВА:

«ХАТЫН-КЫЗГА САБЫР БУЛМЫЙЧА ЯРАМЫЙ»

Гамьле әңгәмә

Тәтеш районының һәрбер авылында «гаилә җитәкчесе» бар. Мондый белгечләр әлегә республиканың бер генә районында да юк. Районның «Ак калфак» һәм «Татар гаиләсе» Бөтенроссия иҗтимагый оешмалары бүлекләре җитәкчесе, «Интернациональный союз женщин» төбәкара иҗтимагый оешмасының Татарстан буенча рәсми вәкиле Рима САФИУЛЛОВА белән авылны, гаиләне саклау, хатын-кызның роле, көчле булу серләре турында сөйләштек.

Илдар Мөхәммәтҗанов

:: Рима Гомәровна, гаилә җитәкчеләре нинди вазыйфаны башкара?
– Әлеге белгечләр районның барлык татар авылларында да бар. Алар – «Ак калфак» җәмгыятенең авыллардагы җитәкчеләре. Әгәр сине хөрмәт итмәсәләр, син башкаларны артыңнан ияртә алмыйсың. Бу белгечләрнең гаиләләрне саклауда файдасы зур булыр дип уйлыйм.

Авыллар тарала, күп гаиләләр аерылыша. Шуңа күрә әлеге проектка ЗАГС хезмәткәрләре белән бергәләп тотындык. Кызлар кияүгә чыга, әмма гаиләдә үзләрен ничек тотасын белми. Вак-төяк сәбәп табып ызгышалар да аерылышалар. Кызганыч, нәтиҗәдә балалар ятим кала. Әти-әни гаебе аркасында газап чигеп яшәргә туры килә. Хатын-кызга сабыр булмыйча ярамый. Язылышкан вакытта ук яшь парларга менә шуны ныклап аңлату җитми. Балага ана назы гына түгел, әти тәрбиясе дә кирәк. Мин төпчек улымны 45 яшьтә таптым. Ирем – җитәкче, бер караганда, бала гел минем янымда. Әмма ул: «Әле ярый әти булды, безне бик җитди итеп тәрбияләде», – диде.

Яшьләрне авылда калдыру мәсьәләсенә дә игътибарны арттырырга җыенабыз. Элек колхозда эшләгән әби-бабайларны чакырып, ферма, кырларда йөртеп, балаларга үзләренең хезмәте, җиргә тугрылык турында сөйләтәсебез килә.

Озак еллар бергә яшәгән үрнәк гаиләләрне дә чакырып котларга исәп. Алма агачыннан ерак тәгәрәми. Кызлар – анага, ирләр атага охшарга тырыша. Эшкә караганда да гаилә мөһимрәк. Кызганыч, эчкечелек, игромания, наркомания кебек тискәре күренешләр авылларга да үтеп керә башлады. Шуңа күрә һәр гаиләне күз уңында тотып, бәладә ялгыз калдырмаска тырышабыз. Эчкән ирләрне машинама утыртам да дәваланырга алып барам. Арада 12 ел эчмичә, гаиләсен саклап, матур итеп яшәүчеләр дә бар.

Тагын мине балаларның көннәр буе телефонда утыруы борчый. Еламасын дип, әниләр өч айлык сабыйга замана уенчыгын тоттыра. Соңыннан аера алмый интегә. Тартып алган өчен, әниләренә кул күтәрүче балалар да юк түгел. Табиблар компьютер уеннарына бәйлелекне наркотиктан да куркынычрак дип әйтә. Игътибар җитмәү нәтиҗәсе бу. Балаларның күбесе начарлыкны да шуңа эшли. Аларның психологиясен яшьтән үзгәртергә кирәк. Менә шушы юнәлештә эш башларга ниятлибез. Психолог белгечлегенә юкка гына укымадым бит. Тәртибе аксаган үсмерләр белән бушлай шөгыльләнергә теләгем бар. Бездә тәрбия эшләре буенча күп эш башкарыла.

> Кайчагында балаларны үзебез үк бозабыз түгелме? Күпләр балалары, оныклары белән вата-җимерә русча сөйләшә. Нигә татарча сөйләшмәскә? Телебезнең бетә баруына үзебездән кала башка берәүне дә гаепли алмыйбыз. Балага телгә, милләткә мәхәббәтне дә кечкенәдән салырга кирәк.

:: Хатын-кызның гаиләдәге роле турында сөйләшик әле. Кайбер нәфис затлар өйдә утырып кына гаиләне сакламакчы. Сезнеңчә, бу дөресме?
– Мөселман ирләре, җитәкчеләр арасында хатыннарына, өйдә утыр, диючеләр дә бар. Бөтен нәрсәң дә бар, телисең икән, матурлык салонына йөр, диләр. Халатыңны киясең дә көн буе кәстрүл юудан башың чыкмый. Хатын-кызга бервакытта да өйдә утырырга ярамый. Ул шәхес булырга тиеш. Тормышта төрле хәлләр килеп чыгарга мөмкин. Ирләре хыянәт итә башласа, аерылышырга туры килсә, андый хатыннар тормышка яраксыз булачак.

Мин «глава хатыны» дип, өйдә утырырга теләмим. Минем – үземнең, Рәмис Хатыповичның – үз эше. Аның кәнәфие мәңгелек түгел бит. Әгәр ирем эшеннән китсә, мин кая барам, кешеләрнең күзенә ничек карыйм? Мин – үзем шәхес. Ир – баш, хатын – муен. Гаиләдә шулай булырга тиеш. Аш пешкән, иремнең өсте чиста, башка эшенә тыгылмыйм. Мин иремә ирек бирдем.

:: Ә сез – эштә нинди хатын-кыз? Агрофирма җитәкләү кыен түгелме?
– Нинди яңа техника, трактор кайта, башта үзем утырам. Комбайнда игеннәрне суктырып карыйм. Чәчү вакытында кырга китәм. Механизаторларны барып кочаклап алам. Гадилек – минем өчен беренче урында.

Эшемдә бухгалтерия кызларыннан башка чәй дә эчмим. «Сез бит инде – директор, глава хатыны», – диләр. Юк, мин алардан аерыла алмыйм. Безнең халык бердәм. Алар белән 26 ел бергә бит инде. Без бер белмәгән Жуково авылына Ульян өлкәсеннән килдек. Элеккеге директор киткәч, эшчеләр, без моннан китәбез, дия башлады. Иң авыры шул булды. Акча эшләп, кесә ягын калынайталар да китәләр икән. Шөкер, гади халыкта ышаныч тудыра алдык. Белгечләребезнең барысы да – яшьләр. Ульяннан килеп эшләүчеләр дә бар. Рәмис Хатыпович – бик көчле җитәкче. Ул булмаса, хуҗалык мондый уңышка ирешә алмас иде. Мин башта хуҗалыкта хисапчы булып эшләдем. Тугыз ел элек ирем район хакимияте башлыгы вазыйфасына билгеләнгәч, юксынудан аның кабинетына кереп утырып эшли дә алмадым…

:: Тормышыгызда да сынаулар аз булмаган. Ничек итеп көчле хатын-кыз булып кала белдегез?
– Жуково авылына күчеп килгәч, башта ике ел ярым балалар бакчасының 12 квадрат метрлы бүлмәсендә яшәдек. Ул вакытта олы улыбыз 5 нче сыйныфта укый иде. Өй җиткездек. 2013 елда өебез янды, кара күмердән башка берни дә калмады. Ульяндагы фатирны да саткан идек, җитмәсә. Ярты ел үткәч, улыбыз Эльвир аварияга эләкте. Бала хәсрәте белән йорт турында уйламадым да. Аңа хәзер 37 яшь. Ун ел инде урын өстендә. Мин башта бик нык еладым, әмма елап кына терелсә, сихәтләнсә икән ул!.. Аны дәваларга көч тә, акча да кирәк. Хәзер Кытайга дәваланырга барырга җыенабыз. Төпчек улыбыз Эмильгә 20 яшь тула. Быел Мәскәүдәге вузның беренче курсын тәмамлады. Абыйсы белән энесе арасында туганлык җепләре бик нык. Тормыш тигез генә бармый шул. Нинди генә сынаулар алдында калса да, хатын-кыз көчле булырга тиеш.

Сәрия МИФТАХОВА

Дәүләт Советында

Татарстаннан күрмәкче

Татарстан – үрнәк. Башка төбәкләрдәге депутатлар республика тәҗрибәсен үзләрендә кулланырга тели. Татарстанның Дәүләт Советында «Заманча шартларда күпбалалы гаиләләрне социаль яклау» дип аталган «түгәрәк өстәл» шул уңайдан оештырылган иде.

Дәүләт Думасының Гаилә, хатын-кызлар һәм балалар мәсьәләләре буенча комитет рәисе Нина Останина Казанны күреп гаҗәпләнүләрен яшермәде.

– Биредә, һәр кешегә уңайлы булсын өчен, шартлар тудырылган. Кая гына барсак та, һәр өлкәдә социаль яктан яклануны күреп сокландык. Авыру балаларга махсус тегелгән киемнәрдән алып, махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаиләләре дә игътибар үзәгендә, – диде ул. – Республиканың һәр кешесенә дәүләттән ниндидер ярдәм бар. Без сезнең тәҗрибәне федераль дәрәҗәдә кулланырга уйлыйбыз. Мондый ярдәм чаралары Россиядә һәр гаиләгә булсын иде. Кайбер законнарга төзәтмәләр кертергә дип торабыз.

Дәүләт Думасы депутаты Татьяна Ларионова Татарстандагы менталь тайпылышлары булган авыруларны тернәкләндерү үзәге турында сөйләде. Андый үзәкләр Россиядә башка юк.

– Кайбер төбәкләрдә балалар өчен мондый үзәкләр булса да, өлкәннәр өчен ул бары тик Татарстанда гына. Авыру балага 18 яше тулганчы барлык ярдәм чаралары да бирелә. 18е тулгач, алар кайчак берәүгә дә кирәксез булып кала. Хәтта гаиләсенә дә кирәксезгә әйләнә. Ә бит аларны тормышка өйрәтергә кирәк. Татарстанда бу үзәк шуны уйлап оештырылды да инде, – ди ул. – Бөтен депутатлар белән бергә эшләгәндә генә без социаль яктан ярдәмгә мохтаҗ булган кешеләргә ярдәм итә алабыз.

Очрашуда гаиләләргә бирелә торган ярдәм чаралары турында да сөйләштеләр. Әгәр дәүләт ярдәм итә икән, балалар да туып тора. Инде моны үзебез дә беләбез. Елдан-ел туганнарыбыз, танышларыбыз арасында өченче һәм аннан күбрәк бала табучылар бар. Алар белә: беренчесе һәм икенчесенә ана капиталы бирелә, өченче сабыйга җир дә эләгә. Кредиты булганнар, аны ябар өчен, дәүләттән 450 мең сум акчага да өметләнә ала. Бала табып, тормыш шартларын яхшыртучылар картлык көнендә ялгыз калмый.

Татарстанның хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Эльмира Зарипова әйтүенчә, соңгы ун ел эчендә Татарстанда күпбалалы гаиләләр саны ике тапкыр диярлек арткан. 2013 елда 24 мең күпбалалы гаилә исәпләнсә, хәзер 42 меңнән артып китә.

– Татарстанда гаиләләр өчен 61 төрле социаль ярдәм чаралары каралган. Шуның 55е – республиканыкы. Болар – дару алу өчен 10 мең сумлык сертификат, бала туганда бирелә торган тартма, күпбалалы гаиләләрнең балаларына бакчага йөрүне бушлай итү, авырлы һәм бала тапкан хатын-кызларга түләнелүче пособие һәм башкалар, – дип санап китте министр. – Балалар туу саны артсын өчен дә төрле чаралар уйлап табыла. Әйтик, авыл җирендә яшәгән хатын-кызга беренче сабыен тапканнан соң – 50 мең сум күләмендә, өченчесе тугач, 100 мең сум акча бирелә. Республикада бу пособиене ел саен 2 меңләп хатын-кыз ала.

Татарстанда Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Сәрия Сабурская исә ирләре һәм әтиләре махсус хәрби операциядә катнашкан гаиләләргә күрсәтелә торган ярдәм чаралары турында сөйләде.

– Мөрәҗәгать булуга ук, тиз арада хәл итәргә тырышабыз. Ирләре махсус операциядә булган хатыннар, аларның балалары һәрдаим күз уңында, – диде ул. – Бу гаиләләргә адреслы ярдәм күрсәтелә. Балаларын бакчага чиратсыз кабул итәләр. Мәктәпләрдә көненә ике тапкыр бушлай кайнар ризык бирелә. Үзләренә һәм гаиләләренә бушлай юридик ярдәм күрсәтелә. Ил җитәкчелеге дә бу гаиләләрне аерым контрольдә тота. Алар үзләрен ялгыз тоймасын өчен, без кулдан килгәнне эшлибез.

Мондый очрашулар кирәк. Татарстанның «Мәрхәмәт» хатын-кыз депутатлары оешмасы җитәкчесе Алсу Нәбиева искәртүенчә, шул рәвешле башта тәҗрибә туплана, аннан исә законнарга төзәтмәләр кертелә. «Без Идел буе федераль округындагы депутат хатын-кызлар белән социаль проблемаларны бергәләп хәл итәбез. Уртак сөйләшүләр аша, тәҗрибә алмашып, федераль законга 110 төзәтмә кертелде», – ди ул.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Студенческий билет № 11804284, выданный ФГБОУ «Казанский Государственный Энергетический Университет», на имя Закировой Наргизы Жахонгировны, считать недействительным в связи с утерей.

САКЛАНУ КИРӘК

Борчыган мәсьәлә

Көн тудымы – чир! Әле яз ахырында гына илдә кызамык йоктыру очраклары арту турындагы хәбәрләр тынычлыкны алган иде. Бу көннәрдә исә чума турында сөйләшә башладылар. Монголиянең 17 төбәгендә 130дан артык инфекция учагы ачыкланган. Бәхеткә, Россиядә бу чирне йоктыру очраклары юк. Әмма белгечләр, илнең Монголия белән чиктәш төбәкләренә андый куркыныч янарга мөмкин, дип кисәтә.

pixabay.com

Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы мәгълүматларына караганда, 2010–2015 еллар арасында дөньяда чума йоктыруның 3248 очрагы теркәлгән. Әлеге чир 584 кешенең гомерен өзгән. Роспотребнадзор идарәсе, бу чир безгә янамый диярлек, дип тынычландыра. Шулай да дөнья хәлен белеп булмый. Шуңа белгечләр чиргә каршы торырга әзерлек эшләрен башлап җибәргән. Илнең Монголия белән чиктәш төбәкләре аерым контрольгә алынган. Сүз уңаеннан, 2017 елдан бирле Россиядә чума йоктыруның бер генә очрагы да теркәлмәгән.

Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының баш эпидемиологы Дмитрий Лопушов фикеренчә, безгә чума янамый. Соңгы арада әлеге чир турында сөйләшүләр күп булуны да елның-елында шушы чорда башкарыла торган планлы кисәтү эшләре дип ачыклык кертте ул.

– Монда җәйге ял чорында, кешеләр күпләп чит илләргә бара башлаган вакытта үтә торган саклык, әзерлек чаралары турында сүз бара. Татарстанда чуманың табигый учаклары юк. Шуңа күрә бу чир безгә янамый. Әлеге чирне авыру тычканнар тарата. Бездә андый территорияләр юк. Россиянең Монголия белән чиктәш төбәкләрендә исә мондый чир таралу куркынычы зур булган урыннар бар. Әмма чума читтән кертелә ала. Шуңа күрә безгә читтән килүчеләр иң элек санитар-карантин тикшеренүе уза, – ди белгеч. – Бездә очрамаса да, республикада әлеге чиргә каршы әзерлек көчле. Медицина тармагында эшләүчеләрне ел саен укытабыз. Ник дигәндә, минем егерме ел эшләү дәверендә республикада бер генә чума йоктыру очрагы да теркәлмәде. Шуңа күрә әлеге чир, аның нинди билгеләр белән узуы, аны ничек дәваларга кирәклеге дә онытылырга мөмкин. Белгечләр моны һәрчак истә тотарга тиеш.

Баш эпидемиолог сүзләренә караганда, чуманың ниндидер үзгә билгеләре юк. Аның инкубация чоры – алты көн. Башка төр күп кенә чирләр кебек үк, чума да 39–40 градуска кадәр температура күтәрелүдән башлана. Кешедән кешегә исә ул, коронавирус кебек үк, һава аша йога.

– Чума белән, нигездә, кимерүчеләрне аулаган, аларны ашаган кешеләр авырый. Безнең өчен болар барысы да – ят күренешләр. Ә шул ук Моноголиядә бу – гадәти хәл. Шуңа күрә анда әлеге чир белән авыручылар саны да күп. Әлеге чир авыру дөяләрне эшкәрткән вакытта да йога ала. Чума йоктырган кешеләрдә бик җитди өзлегүләр дә күзәтелергә мөмкин. Вакытында ачыкланмаса, чума үпкәләрне зарарларга, аерым алганда пневмония башланырга, кан саварга мөмкин. Кызганыч, күп очракта алар үлем-китем белән тәмамлана, – ди белгеч.

Дмитрий Лопушов фикеренчә, күп кенә чирләрнең ара-тирә баш калкытуына гаҗәпләнәсе юк.

– Чәчәк авыруыннан кала, инфекцияле авырулар берсе дә тормышыбыздан югалмады. Алар барысы да әйләнештә. Хәзер санитар шартлар, эчкән су, ашаган ризыкның яхшыруы, вакцинация аркасында бу чирләр очрамый диярлек. Ачыкланган очракта да ул дулкын рәвешендә таралмый. Ни өчен хәзер ара-тирә шул ук кызамык йоктыру очраклары күзәтелә башлады? Чөнки күпләр чиргә каршы вакцина ясатудан баш тарта. Бүген халыкның 95 проценты гына әлеге чиргә каршы вакцина ясаткан. Аны ясатмаучыларның күбесе бу адымын: «Моңа кадәр бу чирнең бер кешедә дә ачыкланганы булмады бит әле. Димәк, берни дә янамый», – дип саный. Менә шул вакцинаны ясатмасаң, күренә башлый да инде, – ди Татарстанның баш эпидемиологы.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

> ✓ Чума иң куркыныч авыруларның берсе санала. Аңа каршы вакцина уйлап табылган **1926** елга кадәр дөньяда әлеге чирне йоктыру **95** процент очракта үлем-китем белән тәмамланган. Хәзер бу сан **10** проценттан да артмый.
> ✓ Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы мәгълүматларына караганда, температура күтәрелү белән беррәттән, чума йоктырган кешенең башы авыртырга, бизгәк тотарга, күңеле болганырга мөмкин. Чирне дәвалап була. Әмма тиз арада ачыкларга кирәк. Юкса ул организмны яшен тизлегендә зарарлый. Шуңа аннан үлү очраклары да еш күзәтелә.

БӘХЕТКӘ ТҮЗЕП КАРА

Тормыш кыйпылчыклары

Хәния Фәрхи: «Сагышларга кем дә түзә, бәхеткә түзеп кара», – дип җырлый иде (Зифа Нагаева сүзләре һәм көе). Тирә-юнебездә нәкъ менә бәхетле чакларының кадерен белми, үкенеп яшәүчеләр дә юк түгел. Бәхетле икәнеңне аңлар өчен, иң элек бәхетнең нәрсә икәнен аңларга кирәктер шул.

Кем нинди дәрәҗәдә күзаллый бит әле. Кемгә – сәламәтлек, кемгә – иминлек, кемгәдер – байлык… Ә кемгәдер «эшкә барасың килеп бару, өеңә кайтасың килеп кайту» зур бәхет булып тоела. Аларның һәркайсында хаклык бар. Тагын бер хаклык: күбебез аларның бәхет икәнен югалткач кына аңлый…

Аңлы, акыллы кешеләрнең дә кайчакта зиһене җитмәгән шушы хакыйкатьне аңларга йодрык кадәрле җан ияләре дә сәләтле була икән. Гаҗәп, әмма бу җәйдә шундый бер очракның шаһиты булырга туры килде.

Автор фотосы

Ишегалдыбызда мәчеләр шактый: уннан артып киткән чаклары да була, кимеп тә китәләр. Бездә генә түгел, хәзер авылда һәр йортта диярлек шул хәл. Быел берничәсе югалды, берсе үлде дә язга җиде ана мәче «генә» калды. Өчесе бер-бер артлы бәбиләсәләр дә, ни хикмәттер, берсе дә балаларын карамады, сакламады. Кайсын кая таратып, үтереп бетерделәр. Бик матур бер песи баласы гына калды. Аны да юньләп караучы булмады. Анасы, ничә карасаң, муеныннан кабып, каядыр өстерәүдә булды. Әйбәтләп урыннар да ясап карадык, аерым тәмле ашатып та… Юк, ана хисе уянмады. Майның салкын бер көнендә, чыксам, лапаста шул песи баласы елап, кычкырып йөри. Үзе лычма. Әллә яңгыр, әллә тирес суына баткан шунда. Калдырсаң, туңып үләчәк инде. Нишләтим икән дип аптырап торганда, ирем эштән кайтып керде. «Мунча җылы бит, алып кереп ю», – ди. Билгеле, юындыргач, көннәр җылынганчы, аны урамга чыгарып булмады. Өйдә генә калдырыр идек, апамның Казандагы оныклары алып кайтып биргән, өйдә генә тота торган бер мәчебез бар. Кадердә, рәхәтлектә яшәп, ул эгоистка әйләнгән булып чыкты: песи баласын яратмады. Тимәсен дип, күп вакыт яшереп тотарга да туры килде. Әнисен табып алып кереп имездертәм дә, калган вакытта үзебез карыйбыз. Ашарга да өйрәттек, башкасына да. Әй, рәхәтләнде сабый өйдә! Ул бу рәхәтлекнең шулкадәр түмен, кадерен белә, аннан шулкадәр биһуш иде – аны күрми, сизми калып булмый, хәтта күзгә яшьләр килә. Әнинең ап-ак урын-җире өстендә җәелеп йоклый, эндәшмәсәң, алмасаң, аннан кузгалмый да; ашарга чакырсаң, йөгереп килә – көн, төн буена ник бер тавышы чыксын! Бөтен килеш-кыяфәте чыгарып ата күрмәсеннәр генә дигән кебек. Гадәттә кечкенә песи балалары, әниләрен эзләп, еламсырап йөри. Моның исендә дә юк! Әнисен дә мин мәҗбүри алып кергәнгә генә имә иде кебек. Аның каравы әнисендә һәм дүрт баласын да карамый үтереп бетергән икенче бер песидә ана инстинктлары уянды. Мияулап өй тирәсеннән китмиләр дә, эзләп, чакырып, тәрәзә төпләренә менәләр, ишек тоткаларына сикерәләр – аптыраш инде менә. Без яратканны күреп, кирәкле, кадерле икәнен аңладылар дип белерсең…

Урамга чыгаргач, инде ул бөтен ана мәчеләрнең уртак баласына әйләнде. Баштарак: «Җидегез бер бала да карый алмадыгыз», – дип тиргәсәм дә, хәзер инде аның кадерлегә әйләнүенә сөенеп туя алмыйм. Ул исә безне дә, өйдәге рәхәт тормышын да онытмады. Күрми калсаң, ишек ачылганда, аяк арасыннан гына өйгә кереп китәргә әзер тора, безне күрсә, әллә каян йөгереп килә. Ашарга биргәндә дә, иң беренче булып йөгереп килеп, иң зур кисәген эләктереп калырга тырыша. Тормыш сабагы…

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

Әйтеп кенә бактым

Яшәсен Сабан туе!

Кеше, еллар узган саен, һәрнәрсәне башкача кабул итә һәм бу табигый. Мәсәлән, балачакта Сабан туе минем өчен иң әүвәл «чүпрәк җыю» иде. Кайбер авылларда аны «ситсы җыю» дип тә йөртәләр. Бу – мәйдан батырларына бүләк җыю инде. Чүпрәк җыючылар, ягъни атка атланган Гата, Ринат абыйлар һәм авыл яшьләре утырган ат арбасы артыннан калмыйча, бөтен авылны йөреп чыга, мәйдан бүләге итеп кемнең нәрсә биргәненә хәтле ятлап бетерә идек. Төрле ярышларда, көрәштә җиңгәннәргә бирелгән бүләкнең кемнеке икәнен кычкырып әйтеп тора башладык хәтта. Ә бүләк дигәннәре – төрле ситсылар, чигелгән сөлгеләр, кулъяулыклар, сирәк булса да күлмәкләр…

Туган ягым Арчада мәйдан караганда, әнә шул Сабантуйлы балачагымны искә төшереп утырдым. Башка районнар үпкәләмәсен, ни дисәң дә, Арча – Арча инде ул. Монда Сабан туйларын һәр елны бераз үзгәрәк итеп уздырырга тырышалар. Быел бәйрәмнең «бисмилла»сы саналган җырлы-биюле тамашада гасырлардан килгән Сабан туеның чын асылы, йола-гадәтләре җанлангандай булды. Казанга кайткач та төрле чыганаклардан аның тарихын өйрәнеп утырдым. Бер мактана башлагач, мактанып бетерим инде: Сабан туе эчтәлеген баетуга мәшһүр якташларым Габдулла Тукай, Галиәсгар Камал да шактый өлеш керткән. Мәйдан уздырганда, халкыбызның борын-борыннан килгән йолаларын саклап калу мәсьәләләрен күтәрә алар. Бу инде Тукай, Камал гына түгел, гомумән, бөтен татар зыялыларының Сабан туен милли бәйрәм дип тануына ишарә. Яшерен-батырын түгел, соңгы вакытларда аны интернациональ бәйрәмгә әйләндерергә теләүчеләр дә табылды. Алай була алмый ул, җәмәгать. Кайбер чыганакларда язылганча, 1834 елда татарлар Казан Сабан туена беренче мәртәбә русларны дәшәләр. Кунак итеп. Аларга: «Кунак булсаң, тыйнак бул!» – димиләр, мәйданда узган бәйге-тамашаларда катнашырга да чакыралар. Тик әлеге бәйге-тамашалар нәкъ менә милли йола-гадәтләргә, әхлагыбызга нигезләнгән була. Һәм катнашучылар шул кысалардан чыга алмый. Бу – татарның зирәклеге, масаймый-нитми генә башка халыкларга үзенең рухи дөньясын күрсәтә белүе, хәтта күпмедер дәрәҗәдә «үз кубызына биетүе» дә. Кунаклар бит безнең җырларны тыңлый, кушылып җырларга тырыша, безнең көйгә тыпырдый, безнең уеннарны уйный, безнең ашлардан авыз итә… Менә сиңа матур гына милли сәясәт!

Әлбәттә, Сабан туена төрле чорларда төрле мөнәсәбәт була. Бүгенге «интернационализм» чалымнарын әйттек инде. Ә XX гасырда үзебезнең үк дин әһелләре арасында Сабан туен зыянлы бәйрәм диючеләр, хәтта «шайтан туе» дип атаучылар да табыла. Андыйлар, мәсәлән, ат чабышларын хайваннарны үлгәнче җәзалауга тиңли. 1865 елда төзелгән «Җәнлекләрне саклау җәмгыяте» вәкилләреннән берсе, Соловьев фамилияле кеше бу «вәхшилек»не татарларда «акыл үсешенең зәгыйфь» булуына бәйли. Алай гына да түгел, Сабан туе кешеләрне әхлакый яктан бетерә бара, ә татарларның «вәхши»леге русларга да күчәргә мөмкин, дигән фикер әйтә.

Петербургта беренче татар газетасы «Нур»ны нәшер итүче Гатаулла Баязитов исеме күпләргә таныш. Менә шул Гатаулла әфәнде әлеге «товарищ»ка акыллы гына, тыныч кына итеп, Сабан туеның татарның төрле бәйгеләр, уеннар оештырып күңел ачуы, үзен тапкырлыкта, җитезлектә сынавы, көч-куәтен күрсәтүе булуын аңлата. Иптәш-товарищ Соловьев, күрәсең, Аурупа ягына күз ташламаган. Юкса ул, корридалар турында да берничә сүз әйтеп, испаннарны пыр туздырган булыр иде. Коррида, кагыйдә буенча, үгез 10 минут эчендә үтерелергә тиеш булган. Ат исә – татар өчен гомер-гомергә тугрылыклы хайван, яшәешендә иптәш-таяныч. Татар үзен саклау өчен ат менгән һәм бүгенге ат чабышлары да – безнең тарих, җитезлектә-батырлыкта сыналу, борынгы бабаларыбызның яшәү рәвеше. Искә төшерик әле, бездә иң артта килгән атка да бүләк бирү гадәте яши, бу да – татарның атка булган хөрмәте. Мондый халык вәхши була аламыни, җүләр!

Бу урында немец галиме Карл Фуксны телгә аласы килеп китте. Германиядә туган бу галим ни өчендер бөтен гомерен татарга, татар бишеге Казанга багышлаган. Казан император университеты ректоры да булып торган. Табиб, этнограф, ботаник, тарихчы, археолог, нумизматның татар тормышын, аның йола-бәйрәмнәрен өйрәнергә алынуы юкка түгелдер дип уйлыйбыз. Димәк, без – бөек халык, башкаларга үрнәк итеп сөйләрлек, күрсәтерлек тарихыбыз, үзенчәлекле яшәү рәвешебез бар. Карл Федорович Сабан туйларын да өйрәнгән. Аның көрәштә җиңүчегә йә берәр бүләк, йә акчалата приз бирелүе турында язганы кызык тоелды, уйландырды. Акчага әйләндерелгән бүләк нибары 10–20 тиен булган. Карл Федорович яшәгән чорда, ягъни патша заманында Россиядә бер сыер өч тәңкә торган, диләр. Димәк, 10, 20 тиенгә әллә ни алып булмаган. Күрәсең, элек-электән кешене акча түгел, ә «Сабан туе батыры» дигән исем күбрәк кызыксындырган. Бу исем бүген дә иң мактаулы санала, һәрхәлдә, шулай булырга тиеш. Без, мәсәлән, Арча пәһлеваннары Әхәт батырны (Әхәт Закиров), Рәдис Сәйфуллинны машина яки суыткыч алган көрәшче дип түгел, Сабан туе батыры дип хөрмәт белән искә алабыз. Милли бәйрәмнәр дә, Болгар чорларыннан ук килгән Сабан туйлары да кыйммәтле бүләкләр өләшү урыны түгел, ә татар рухы сакланган, аның көч-куәте уйнаган, җыр-моңнары яңгыраган мәйдан булып яшәсен иде. Бу мәйдан, шөкер, киңәйгәннән-киңәя, дөньяның төрле кыйтгаларына күчә бара.

Сабан туйлары яшәсә – без, без яшәсәк, Сабан туйлары да яшәр.

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

«Арча хәбәрләре» газетасындагы каләмдәшләребез җибәргән рәсемгә күз салыгыз әле. Ул узган гасыр уртасында Арча районы Казанбаш авылында төшерелгән. Аңлатма язып тормасак та, бу рәсем Сабан туйларының буыннардан-буыннарга күчеп баручы бәйрәм икәненә бер ишарә сыман.

Газетаның киләсе саны 30 июньдә чыга.

Илдар Мөхәммәтҗанов

«Татар-информ»

2023
ГОД НАЦИОНАЛЬНЫХ КУЛЬТУР И ТРАДИЦИЙ
МИЛЛИ МӘДӘНИЯТЛӘР ҺӘМ ГОРЕФ-ГАДӘТЛӘР ЕЛЫ

Лилия ГЫЙМАЗОВА

КАЙТУ

Быелгы Казан Сабан туе хәтерләрдән тиз генә җуелмас. Аның оештыру дәрәҗәсе һәм масштабы да, башка сәбәпләр дә бу көнне истә калдырырлык итте. Барлыгы 175 мең кешене җыйган башкала Сабан туенда без дә йөреп кайттык.

Тынычлык бистәсе

«Киемеңә карап каршы алалар, акылыңа карап озаталар» мәкаленә тугры калып, сүзебезне Сабан туена килүчеләрнең өс-башын барлаудан башлыйк әле. Милли кием, дөресрәге, аны көндәлек тормышка, һич югы бәйрәмнәргә кайтару турында соңгы арада бик күп сөйләшәбез бит инде. Быелгы Казан Сабан туена да милли киемнән килергә киңәш иткәннәр иде. Бу киңәшкә колак салганнармы, юкмы – иң элек шуны барладык.

Сабан туе мәйданына элдерүче электричкада ук чигүле яулык, алъяпкыч кигән, милли орнаментлар белән бизәлгән букча аскан ханымны, кечкенә калфаклы кызчыкларны, түбәтәйле абыйларны күргәч, җанга бигрәкләр дә рәхәт булып киткән иде үзе. Бәйрәмнең үзендә мондый күренешне сирәгрәк очратырга насыйп булды шул. Дөрес, калфаклы туташханымнар, түбәтәйле абыйлар гел очрамады түгел. Өстәвенә волонтерлар килгән һәр кешегә юка гына тукымадан эшләнгән изү, милли бизәкле кулъяулыклар өләшеп торды. Калфаклы яшь кызларны күрү бигрәк тә сөендерде. Балаларын матур итеп киендергән һәм үзләре дә киемнәрендә милли элементларга өстенлек биргән гаиләләр дә бар иде. «Театрга барганда да, һич югы милли яулыгым үзем белән була. Кечкенә булса да, кызым да кызыга, аңа да шундый кирәк. Безнең бизәкләр бигрәк матур, зәвыклы бит. Аларны заманча итеп киемнәргә, бизәнү әйберләренә өстәп җибәрүче дизайнерларыбыз да күп. Бәйрәмнәрдә булса да шулай матур булып йөрик, кем икәнебезне күрсәтергә оялмыйк», – дип сөйләде безгә Казаннан Алсу ханым.

Республиканың рәсми затлары арасында да бу бәйрәмгә ныклап әзерләнүчеләр күренде. Ләкин бу гадәтне – милли кием киюне массакүләм итү өчен вакыт күбрәк кирәктер ул. Матур үрнәк күрсәтеп, милли кием турында күбрәк һәм үтемлерәк сөйләнсә, иң мөһиме, бу индустриянең үсеше өчен күбрәк эшләнсә, белеп булмый, Сабан туйларыбызда гади киемнән килгән кешене табып та булмас әле.

Хуш килдегез – ашап китегез!

Кеше тикшерүдән туктап, ишегалларына рәхим итик. Башкала Сабан туена республика районнарының шул рәвешле әзерләнүе – шулай ук тагын бер традиция. Тынычлык бистәсендәге Каенлыкта 11 район 11 ишегалды өчен җавап тотты. Сабан туеның иң күңелле мизгелләре шул ишегалларында булды, дисәк, ялгышмабыз. Районнарга үзенчәлекләрен дә күрсәтеп, милли ашлар да әзерләп, остаханәләр һәм уеннар да оештырып, ул уеннарның тарихын сөйләп, халыкның күңелен дә күрергә шактый тырышырга туры килгәндер. Һәркайсында халык уен коралларында матур көйләр уйнап, җырлатып, биетеп каршы алдылар, ашатып, эчертеп, озатып калдылар.

Фикер

Алинә ЗАҺИТОВА,
Олимпия чемпионы, Россиянең атказанган спорт остасы:
– Бу күркәм бәйрәмгә чакырулары өчен Татарстан җитәкчелегенә рәхмәт әйтәсем килә. Мин бик теләп риза булдым. Мондый бәйрәмнәрдә күптән булганым юк иде инде. Алар чын мәгънәсендә халыкны берләштерә. Сабан туе – татар халкының зур байлыгы ул. Мин дә читтә кала алмадым.

Әйтик, Арча ишегалдына кереп, өчпочмак пешереп карап, аның төрле рецептлары белән таныштык. Бер кырыйда күн мозаикасы буенча остаханә эшләде. Ишегалдының нәкъ уртасында олысы-кечесе капчык киеп сикерешә. Боларның барысын да кечкенә генә күлдә чәчен тарап утыручы Су анасы күзәтеп торды.

Яшел Үзән әзерләгән ишегалдында ипи-тоз түгел, җиләк белән каршы алдылар. Монда кергән һәркемнең игътибары 173 килолы чәкчәккә төбәлгән иде. Аның авырлыгы Татарстанда гомер кичерүче халыклар саны белән тәңгәл килсә, 4001625 өлештән торуы республикада яшәүче кешеләрнең гомуми санына туры килә. Менделеевскида яшәүчеләр дә күчтәнәчсез килмәгән. Бәйрәмгә килгән һәр кешегә җитсен диптер инде, 1634 килолы бавырсак алып килгән иде алар. Рекорд куйган бу бавырсакны 30 кеше 3 көн буе әзерләгән. Соңыннан аны һәркем авыз итә алды.

Лаешлыларның ишегалдында кунакларны, гармун уйнап, район башлыгы Илдус Зарипов үзе каршы алды. Монда кергән ир-атлар, ни сәбәпледер, пәрәмәч пешереп карарга ашыкты, ә балчыктан чүлмәк ясаучы оста янында күбесенчә хатын-кызлар күренде. Ә Зәй ишегалдында җәелгән киң келәмдә, Сабан туе рәсми төстә ачылганчы, көрәшчеләрне сыный тордылар.

Кыскасы, төп сәхнәгә барып җиткәнче, Сабан туена килүчеләрнең тамаклары тук, күңелләре күрелгән иде инде. Мич коймагына Идел буе чиратка баскан апа-абыйлар тантаналы ачылышның башланганын сизми дә калды…

Беренче бură зна

Ә без исә шунда ашыктык. Быел бит бәйрәмнең керешенә игътибарны мулдан биреп, эчтәлегенә басым ясаячакбыз, дип вәгъдә иткәннәр иде. Һәм бу сизелде дә. Төрки халыкларны барлыкка китерүче алиһә – Ак Ана турындагы риваятькә нигезләнгән бу тамаша Сабан туеның, бүгенгә кадәр килеп җиткән уеннарының тарихын да, мәгънәсен дә сөйләп бирде.

Ат чабышы. Ак Ана халкын Идел һәм Чулман елгалары кушылган җиргә урнаштыра. Иң беренче эш итеп, бу җирне яман иядәрдән арындырырга кирәк була. Аларны атларга утырган изге ияләр куаларга тотына. Ат чабышы әнә шуннан килеп чыккан икән.

Гер күтәрү. Җир яман көчләрдән чистартылгач, анда ни дә булса чәчү өчен, ташлардан да арынырга кирәк. Ир-атлар, шушы ташларны күтәреп ташыган арада, үзара көч сынашкан. Иң көчле булып танылганына беренче бураз-наны ясау хокукы бирелгән. Гер күтәрүнең килеп чыгышын шулай аңлаттылар.

Колгага менү. Монысы инде яңа көн туу турында хәбәр итүдән килеп чыккан. Көн саен берәү биек колгага менеп, кояш чыкканын караган да башкаларга хәбәр салган.

Менә шулар турында сөйләгән, халкыбызның электән үк тырыш, үҗәт һәм бердәм булуын күрсәткән, думбра, кыл-кубыз, курай, дәф, ятаган тавышлары белән үрелеп барган тамаша иде ул. Баш режиссер Айдар Җаббаров җитәкчелегендәге зур иҗади төркемгә җуелган мәгънәләрне кире кайтарып, һәр нәрсәнең артында тирән тарих ятуын күрсәткәннәре өчен рәхмәт әйтергә генә кала.

«Ысыахка чакырулары өчен рәхмәт!»

Мондый ачылыш Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнехановны да битараф калдырмады булса кирәк.

– Якутиядәге дус-иптәшләребезгә үзләренең Ысыах бәйрәмнәренә чакырулары өчен рәхмәт. Бик матур, тарихка алып кайта торган бәйрәм ул. Үзебезнең Сабан туеның да шундый матур булуын телибез. Безгә бу бәйрәмдә милли мәдәниятебезнең тарих сәхифәләренә мөрәҗәгать итү җитми иде. Ә бүгенге бәйрәмне оештыручыларга бик зур рәхмәт! Киләчәктә дә шушындый бай тарихыбызны, гореф-гадәтләребезне саклап, бәйрәмнәрдә күрсәтербез дип ышанам. Алдагы елларда да очрашып, аралашып, тәмле ризыкларыбызны авыз итеп, төрле уеннарда катнашып, бәйрәм итәргә насыйп булсын, – диде ул, бәйрәм белән котлап.

Якутиядәге дуслар, димәктән. Казан Сабан туе кунакларын Саха Республикасы Хөкүмәте рәисе Андрей Тарасенко да котлады.

– Безнең өчен иң мөһиме – үзенчәлекле, күпгасырлы мәдәниятебезне саклау. Сабантуй һәм Ысыах – халыкларның дуслыгын һәм үзенчәлеген символлаштыра торган бәйрәмнәр ул, – диде ул.

Аккош күле

Елдагыча, хезмәт туе Казанның Аккош күле буенда да гөрләде. Башкала халкын һәм кунакларын Габдулла Тукай әкиятләреннән «качкан» Шүрәле, Су анасы, Былтыр каршы алды. Рәт-рәт тезелеп киткән Чистай, Яңа Чишмә, Кама Тамагы, Әлки, Апас һәм Югары Ослан районнарының ишегалларында төрледән-төрле уеннар, тәм-том тулы өстәлләр, остаханәләр әзерләнгән иде. Монда да килгән һәркемне «тере» музыка озата барды. Ә бәйрәмнең тантаналы өлешендә кунакларны Рөстәм Миңнеханов исеменнән Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин тәбрикләде.

– Бүгенге бәйрәмдә без Татарстанның төрле почмакларында узган Сабан туйларына йомгак ясыйбыз. Татарларның милли бәйрәмендә республикада яшәүче барлык милләт вәкилләре дә катнашты, – диде ул. – Татарстан борынгыдан килгән һәм хезмәт кешеләрен берләштерә торган бәйрәмебез – Сабан туеның традицияләрен кадерләп саклый. Мондый бәйрәмнәр аша без киләчәк буынга һәр халыкның милли мәдәниятен, халыкара татулыкны саклауның әһәмиятен күрсәтәбез.

КАЗАН САБАН ТУЙЛАРЫ БАТЫРЛАРЫ

Тынычлык бистәсе – **Лениз Абдуллин**
Аккош күле – **Фирдүс Зәйнуллин**
Дәрвишләр бистәсе – **Раил Нургалиев**

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5315 данә
Гомуми тираж – 14253 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 290

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кулъязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+